- уку бинасы һәм ул урнашкан территориянең, кабинетларның санитария һәм янгыннан саклану нормаларына туры килүе;
- укытучыларның һәм башка хезмәткәрләрнең хезмәтен саклау;
- ашханә, спортзал, бассейн һ.б.ш. урыннарда җиһазларга сакчыл караш, алардан тиешенчә файдалану, мәктәпнең эчке кагыйдәләрен үтәү;
- дәресләрдә файдалану өчен, китапханәдә тиешле күләмдә китаплар, дәреслекләр булдыру;
- компьютер классларыннан укучыларның яшь үзенчәлекләренә карап файдалану;
- телевидение һәм Интернет чараларыннан урынлы файдалану;
- укучыларның физик мөмкинлекләрен исәпкә алып, дистанцион уку формасыннан файдалану;
- башлангыч сыйныфларда татар теле дәресләрендә кулланыла торган төрле таратма һәм күрсәтмә әсбапларның санитария нормаларына туры килүләрен тәэмин итү;

сәләтле укучыларга аерым якын килеп, аларны төрле өстәмә эшләргә җәлеп итү.

**Литературное чтение на родном (татарском) языке**
**(татар төркемнәре).**

(Программа әдәби әсәрләр белән эшләү юллары, алымнары белән таныштыра, шул ук вакытта укытучыга иҗади эшләү мөмкинлеге дә калдыра).

**Халык авыз иҗаты әсәрләре**

Халык аваз иҗаты турында гомуми күзаллау. Авторларының булмавы, телдән сөйләм, гамәли уен характерындагы кече жанр әсәрләре. Бишек җырлары, санамыш, табышмак, тизәйткеч, эндәшләр. Әйләнмәле һәм чылбыр әкиятләре. Халык авыз иҗатының табышмак, әйләнмәле әкият кебек төрләрен гамәли үзләштерү.

Сурәтләнгән вакыйгаларга карата автор фикере (әсәр исеме, геройларга характеристика, автор бәяләмәсе).

**Хайваннар турында әкиятләр.** Әкиятләр турында гомуми күзаллау. Татар халкының хайваннар турындагы әкиятләрендә төп герой, аның характеры. Россия халыклары әкиятләре. Хайваннар турында әкиятләрнең, гасырлар кичеп, хәзерге көнгә кадәр килеп җитүе: бик борынгы әкиятләр, борынгы әкиятләр, әкияти вакыйгалар.

Әкиятләрнең тәрбияви роле. Геройларның характеры, аларның акыл-фигыльләре, һәрвакыт ярдәмчел, киң күңелле булуларына игътибар итү, ишарә ясау. Күчмә сюжетлар.

**Тылсымлы әкиятләр.** Сюжет куелышы. Тылсымлы дөньядагы предметлар, әкияти төсләр, тылсымлы булышчылар. Борынгы заманнарда дөньяны танып белү (төрле көчләр, кешенең хайванга, үләнгә, табигать күренешләренә әверелүе). Тылсымлы әкиятләрнең төзелеш үзенчәлеге (вакыйгаларның чылбыр рәвешендә үрелеп баруы, кабатлаулар). Тылсымлы әкият геройлары. Тылсым дөньясы, булышчылар, тылсымлы предметлар, тылсымлы саннар (3, 7, 13, 40). Әкият геройларының тылсым дөньясына сәяхәт итүе, сынаулар аша үтүе, явыз көчләрне җиңүе, гаделлекнең тантана итүе. Дөнья халыклары әкиятләре.

**Тормыш-көнкүреш әкиятләре.** Тормыш-көнкүреш әкиятләренең килеп чыгышы. Тылсымлы әкиятләрдән аермалы яклары. Әкиятләрдә проблемалар, үгет-нәсыйхәт бирү, юмор хисе.

**Автор әкиятләре.** Автор һәм халык әкиятләрендә сюжет-композиция охшашлыгы; яңа мәгънәви төсмерләр бирү. Татар, рус, дөнья классикасында халык әкиятләре һәм автор әкиятләрендә охшашлык: сихри көчләрне җиңү юллары (халык әкиятләрендә), ярату хисенең көче (автор әсәрләрендә).

**Риваять, бәет, мифлар турында гомуми күзаллау булдыру.** Риваять, бәет, мифларда кешеләр тормышының чагылышы, табигый көчләрнең кешеләргә ярдәмгә килүе. Кешелек дөньясы һәм тылсымлы дөнья арасындагы бәйләнеш.

**Мәкальләр.** Мәкальләр – халыкның тормыш тәҗрибәсеннән тупланган акыллы сүзләр. Мәкальләрне төрле ситуацияләрдә урынлы куллана белергә күнектерү. Төрле халыкларның мәкальләре, аларның охшашлыгы. Әкият, мәсәл, хикәяләрнең, иллюстрацияләрнең эчтәлегенә туры килә торган мәкальләрне дөрес сайлау.

**Автор әсәрләре**

Тылсымлы шигъри әкиятләр (Г. Тукай. «Су анасы», «Шүрәле» һ.б.). Аларда халык әкиятләре белән сюжет бәйләнеше, композиция үзенчәлеге. Автор әсәрләрендә һәм халык әкиятләрендәге сюжет кулланылышы (капма-каршы ике дөнья, булышчылыр, тылсымлы төсләр). Автор әкиятләрендә, нәкъ халык әкиятләрендәгечә, вакыйгаларның кабатлануы, чылбыр рәвешендә төзелүе, аерым сүзләрнең ритмик кабатланып килүе. Автор теленең кабатланмас матурлыгы.

**Мәсәлләр**

Мәсәлләрнең ике өлештән – сюжеттан һәм моральдән (үгет-нәсыйхәт, әдәп-әхлак кагыйдәләре) торуын аңлату. Мәсәлләрнең хайваннар турында әкиятләрдән килеп чыгышы

һәм гасырлар дәвамында үсеше. Мәсәл моралендә мәкальләр куллануның тәрбияви роле. Татар язучыларының мәсәлләре белән танышу.

**Әдәби жанрлар**

Жанрлар турында гомуми күзаллау булдыру; хикәя, шигырь.

**Хикәя.** Хикәянең исеме. Ике образны чагыштырып сөйли белү. Әсәр геройларына карата үз фикереңне белдерү. Жанр үзенчәлеге: сурәтләнгән вакыйгаларның тормышчанлыгы, әхлак кануннарына туры килүе, уйлап табучанлык. Әсәр исеменең төп мәгънә һәм эчтәлек белән туры килүе. Хикәя геройлары, аларның портретлары, характеры, сөйләм һәм вакыйгалар аша чагылышы. Хикәядә авторның үз геройларына мөнәсәбәте. Хикәя герое. Характер һәм тойгылар үзенчәлеге. Геройларның характерына чагыштырма анализ. Авторның геройга, вакыйгаларга, күренешләргә мөнәсәбәтен сиземли алу, үз фикереңне әйтә белү. Хикәяләрдә автор билгеләмәсе: герой портреты, катнашучы геройларга характеристика, пейзаж һәм интерьер сурәтләнеше, геройны чолгап алган тирәлек. Әкият һәм хикәя жанрының аерымлыклары (бары тик күзәтелә генә): әкияттә кискен бирелә, ә хикәяләрдә композициянең уйланылмаган, алдан күрелмәгән борылыш алуы. Жанрларның максаты төрле булуга игътибар итү: әкиятләрдә укучы-тыңлаучыга табигатьнең югары көчләре тәэсире, геройларның халәте бирелсә, хикәяләрдә теге яки бу вакыйгада геройларның характерын ачу күзәтелү. Хикәя жанрының үзенчәлекле якларын күзәтү: а) хикәяләрдә вакыйгалар агышы (әсәр героеның характерын ачыклау өчен кызыклы хәлләр); ә) герой характерының катлаулылыгы; б) вакыйга һәм хәлләрнең киеренкелеге; в) әсәрнең сәнгатьле теле. Әсәрдә берничә сюжет сызыгы белән вакыйгалар бирелеше, геройларның кичерешләре, җиңүләре.

**Шигырь.** Дөньяны шагыйрьләр күзлегеннән чыгып танып белү: шагыйрьнең матурлыкны тоя белергә өйрәтүе. Рифма белән танышу: аны сиземли, таба, куллана белергә күнектерү. Кеше һәм табигать бергәлеге. Әйләнә-тирә дөнья матурлыгының шагыйрь өчен илһам чишмәсе булуына инандыру. Шигырьдә чагыштыру, сынландыру, эпитет. Автор әсәрләрендә һәм халык авыз иҗатында охшашлык. Чагыштыру, контраст, җанландыру кебек гади әдәби алымнарны таба белү. Җанлы сөйләмнең мөһим чараларын үзләштерү күнегүләре: темп, тавыш көче, тон, сөйләм мелодикасы (тавышны күтәрү, түбәнәйтү).

Лирик геройның («Катнашучы герой», «Автор») эчке дөньясын шигъри формада ачып бирү юллары: әйләнә-тирә табигатьне сурәтләү, хис һәм тойгылар чагылышы. Әсәр геройларының сөйләм үзенчәлекләрен билгеләү, аларның эш-гамәлләрен, тирә-юньгә, дөньяга карашларын чагыштырып карау, үзеңнең һәм авторның геройга мөнәсәбәтен ачыклау. Тексттагы сүзләренең мәгънә төсмерләрен аера белү һәм аларны сөйләмдә куллану, сурәтләү чараларын (чагыштыру, эпитет, метафора, фразеологик берәмлекләр, каршы кую, кабатлаулар) тану һәм аңлау. Төрле ел фасылларын чагыштырып, дөньяның күп төсле, формаларның күп төрле булуын аңларга ярдәм итү, матурлыкка тиешле хисләр белән җавап бирергә, оригиналь һәм стандарт булмаган фикерләргә кызыксыну уяту. Гади предметларның гадәти булмаган якларын ачу.

Геройның эчке дөньясын аның әйләнә-тирә дөньяны танып белүе аша күрсәтү. Шагыйрьләр иҗат иткән дөнья белән чынбарлык арасындагы охшаш һәм аермалы якларны билгеләү. Шигырьләрне укыганда әдәби сурәтләү чараларын (чагыштыру, җанландыру, капма-каршылык, лексик һәм композицион кабатланулар) эзләп табу. Авторларның иҗат алымнары турында күзаллау булдыру. Диалогик һәм монологик сөйләмне үстерү.

Әдәби әсәрләрнең башка сәнгать әсәрләре белән бәйләнеше.

**Библиографик культура**

Дәреслектә җиңел генә ориентлашырга өйрәтү: эчтәлектән кирәкле әсәрне тиз генә эзләп таба белү. Кече яшьтәге мәктәп баласының дәрестән тыш эшчәнлеген оештыру: өй, мәктәп китапханәләреннән файдалану. Фән буенча сүзлек, белешмә әдәбият, вакытлы матбугат белән эшләү. Балалар китабы белән эшләү. Китапның төп элементларын аеру: китап тышлыгы, китап төпсәсе, битләре. Китапны саклап тоту күнекмәләре булдыру.

Тематик һәм монографик җыентыклар турында күзаллау булдыру. Төрле тематик жыентыклар төзү күнекмәләре бирү. «Сайланма әсәрләр» төшенчәсе бирү. Теге яки бу язучы, шагыйрь иҗатын өйрәнгәннән соң, аның әсәрләреннән нәни жыентыклар төзү. Китапханәләрдән файдалана белү осталыгын үстерү, тәкъдим ителгән исемлек буенча китаплар сайлый белергә өйрәтү.

Әдәби китапларда җиңел ориентлашу. Китап ахырында бирелгән эчтәлек белән эшләү. Китап элементлары: титул бите, аннотация, китапның рәссам-бизәүчеләре һ.б. турында өйрәнүне дәвам итү. Аерым әсәр яисә китапка аннотация яза белергә күнектерү. Сайланма әсәрләр турында белешмә бирү. Мәгънәсе аңлашылмаган яисә авыр язылышлы сүзләрне сүзлекләрдән табарга өйрәтү. Язучы, шагыйрьләр турында чыгышлар ясау. Китапханәдә ориентлашу.

Аңлап һәм сәнгатьле уку күнекмәләрен үстерү. Телдән һәм язма сөйләм күнегүләре. Аралашу культурасын ныгыту. Темага карата, әсәр буенча үз фикерләреңне төгәл әйтә белү.

**Уку , сөйләү, тыңлау күнекмәләре формалаштыру**

Укучыларны тиз һәм йөгерек укырга гадәтләндерү. Укыганда орфоэпия нормаларын төгәл саклау, дөрес тавыш төсмерләре (тавыш көче, темпы) белән укырга өйрәтү. Аңлап һәм сәнгатьле уку күнекмәләре булдыру. Укуга карата таләпләрне төгәл үтәү: кычкырып укуның дөреслеге, сәнгатьлелеге, укуның тизлеге.

Юмористик һәм җитди характердагы әсәрләрне кычкырып, яттан укыганда эмоциональ характерын чагылдыру. Тавыш төсмерләре – интонация, тон, тавыш көче, темп, пауза, логик басым, сүзсез мимика, хәрәкәтләрне бирү күнекмәләре.

Текстларны анализлаганда сәнгатьлелек чараларын табарга күнектерү. Сурәтләү чаралары турында беренчел күзаллау булдыру, кабатлауларның мәгънәсенә төшенү, тавышның сәнгатьлелеген ачыклау: рифма, ритм тою күнекмәләре.

Сәнгатьле уку күнекмәләре формалаштыру (интонация, тон, темп саклап кычкырып уку). Автор бирергә теләгән картинаны күзаллау. Эчтән укый белергә күнектерү. Чылбыр рәвешендә укыганда үз урыныңны белеп, чират буенча уку. Укылган әсәргә анализ ясау күнекмәләре.

**Уку һәм сөйләм үстерү буенча тәкъдим ителә торган темалар**

1. Табигать һәм без (ел фасылларына карата шигъри һәм чәчмә әсәрләр).
2. Бәхетле балачак.
3. Әдәп-әхлак кагыйдәләре.
4. Халык авыз иҗаты (әкиятләр, табышмак, такмаклар, санамышлар, мәзәкләр).
5. Әкиятләр (төрле милләт халыклары әкиятләре, язучылар иҗат иткән әкиятләр).
6. Туган ил, туган җир.
7. Безнең дусларыбыз.
8. Гаиләдә туганлык хисләре.
9. Ел фасыллары бизәкләре.
10. Туган якның серле табигате.
11. Без – әкият дуслары.
12. Шигърият дәфтәре.
13. Балачак мизгелләре.

**Укытуны материаль-техник һәм мәгълүмати яктан тәмин итү**

«Әдәби уку» предметын өйрәткәндә, балаларның матур әдәбият һәм халык авыз иҗаты белән кызыксынуларын, иҗади сәләтләрен, мөстәкыйль фикерләү, фикерләрен дәлилли алу осталыгын үстерү һәм предметны тирәнтен өйрәтү максатыннан, түбәндәге материаль-техник чаралардан файдалану мөмкинлеге күздә тотыла:

- халык авыз иҗаты үрнәкләре;
- тарихи чыганаклар;
- сынлы сәнгать әсәрләре;
- тема буенча музыкаль әсәрләр;

- күрсәтмә әсбаплар;
- мультимедиа укыту программалары;
- электрон дәреслекләр;
- Интернет материаллары;
- электрон китапханә;
- компьютер программалары;
- укучыларның белемнәрен тикшерү программалары;
- сүзлекләр;
- белешмә материаллар;
- татарча сайтлар;
- балалар өчен чыгарылган газета һәм журналлар;
- яңа әдәби китаплар;
- аудио һәм видеоәсбаплар;
- интерактив тикшерү программалары;
- лингафон кабинеты.

**Родной (татарский) язык и литературное чтение на родном (татарском) языке (рус төркемнәре).**

(Программа әдәби әсәрләр белән эшләү юллары, алымнары белән таныштыра, шул ук вакытта укытучыга иҗади эшләү мөмкинлеге дә калдыра).

**1 нче сыйныф**

**Сөйләм эшчәнлегенең төрләре буенча күнекмәләр**

***Сөйләү***

– сөйләм әдәбе үрнәкләрен кулланып, гади диалогларда катнашу;
– предметны, персонажны яки рәсемне тасвирлау;
– үзе, гаиләсе, дусты, шәһәре (авылы), бәйрәмнәр, ял һәм спорт турында сөйләү;
– текстны укып яки тыңлап, эчтәлеге буенча сорауларга җавап бирү.

***Тыңлап аңлау***

– аралашу барышында укытучының һәм сыйныфташларның сөйләмен ишетеп аңлау, вербаль яки вербаль булмаган рәвештә җавап кайтару;
– аудиоязмадагы кечкенә хәбәрләмәнең төп эчтәлеген әйтеп бирү.

***Уку***

– татар сүзенең график образын аның авазлы образы белән чагыштыру;
– укуның орфоэпик һәм интонацион нормаларын үзләштерү;
– өйрәнелгән тел материалына нигезләнгән кечкенә күләмле текстны сәнгатьле итеп һәм әйтелеш нормаларын саклап уку;
– өйрәнелгән тел материалына нигезләнгән кечкенә күләмле текстларны эчтән уку, кирәкле мәгълүматны табу һәм аңа бәйле гади нәтиҗәләр ясау.

***Язу***

– татар алфавитындагы барлык хәрефләрне каллиграфик дөрес язу;
– сүзләрне, сүзтезмәләрне, гади җөмләләрне күчереп язу;
– үрнәк буенча котлау язу;
– өйрәнелгән тема буенча сорауларга язмача җавап бирү.

**Тел чаралары һәм аларны куллану күнекмәләре**

***Сөйләмнең фонетик ягы***

– авазларны ишетеп аера һәм дөрес әйтә белү;
– сүзләрдә басымны дөрес кую;
– җөмләләрне дөрес әйтү;
– татар алфавитын яттан әйтү;
– сүзләрне яки җөмләләрне үзгәртмичә күчереп язу;

– актив үзләштерелгән сүзләрне дөрес әйтү һәм язу.

***Сөйләмнең лексик ягы***

– аралашу барышында, коммуникатив максаттан чыгып, актив лексикадан файдалану;

– өйрәнелгән аралашу темаларына караган лексик берәмлекләрне һәм сүзтезмәләрне таный белү.

***Сөйләмнең грамматик ягы***

– өйрәнелгән грамматик формаларны сөйләмдә дөрес куллану һәм тексттан табып әйтү;

– өйрәнелгән җөмлә калыпларын сөйләмдә куллану.

**Социаль-мәдәни күнекмәләр**

Аралашу кагыйдәләре һәм гыйбарәләрен, иң гади җөмлә калыпларын балалар фольклоры үрнәкләрен (санамышлар, тизәйткечләр, табышмаклар, мәкальләр, җырлар) гамәли үзләштерү.

**Махсус күнекмәләр**

Ике телле сүзлекләрдән, белешмә материаллардан файдалану, мультимедиа әсбапларыннан файдалану; сүзлекчә (сүзлек дәфтәре) алып бару.

**Сөйләмнең предмет эчтәлеге**

Телдән һәм язма сөйләмнең эчтәлеге белем һәм тәрбия бирү максатларыннан, шулай ук укучыларының яшь үзенчәлекләре һәм мәнфәгатьләреннән чыгып билгеләнә.

*Исәнме, мәктәп!*
*Гаилә һәм мин*
*Сәламәт бул!*
*Шәһәрдә*
*Уенчыклар кибетендә*
*Киемнәр кибетендә*
*Ашамлыклар кибетенд*
*Ел фасыллары*
*Яңа ел бәйрәме*
*Без кунакка барабыз*
*Без уйныйбыз, җырлыйбыз*
*Йорт хайваннары һәм кошлары*
*Кыргый хайваннар һәм кошлар*
*Әниләр бәйрәме*
*Бакчада*
*Без спорт яратабыз*
*Җәйге ял*

**Тел материалы**

*Фонетика*. Татар алфавиты. Аваз-хәреф бәйләнешләре. Транскрипция билгеләре. Татар телендәге үзенчәлекле авазлар. Үзенчәлекле сузык һәм тартык авазлы сүзләр. Калын һәм нечкә әйтелешле сүзләр. *Я, ю, е* хәрефләре белдергән авазлар. Сүз басымы. Хикәя һәм сорау җөмләләр.

Уку һәм язу кагыйдәләре. Сүзне юлдан-юлга күчерү. Җөмләне баш хәрефтән яза башлау. Ялгызлык исемнәрне баш хәрефтән язу. Җөмлә ахырында тыныш билгеләре (нокта, сорау билгесе).

*Лексика.* Аралашу темаларына караган актив лексика. Сөйләм әдәбе берәмлекләре. Алынма сүзләр (мәсәлән, *парта, пенал*).

*Грамматика. Кем? Нәрсә?* сорауларына җавап бирә торган сүзләр. Исемнәрнең сан һәм килеш белән төрләнеше. Исемнәргә сан, килеш кушымчаларның ялгану тәртибе. *-ныкы/-неке* кушымчалы исемнәр. Ялгызлык исемнәр (кеше исемнәре, шәһәр исемнәре). Лексик темаларга караган сыйфатлар. *Сыйфат + исем (күплек сан)* төзелмәсе. Зат, сорау, тартым алмашлыклары. Микъдар саннары (30 гә кадәр). *Сан + исем* төзелмәсе. Тәртип саннары (30 гә кадәр). Хәзерге

заман хикәя фигыльнең барлыкта зат-сан белән төрләнеше. Вакыт рәвешләре (*бүген, иртәгә, кичә, иртән, кичен).* Бәйлекләрнең исемнәр белән кулланылышы (*бәйрәм белән, шәһәр турында).* Кисәкчәләр (*-мы/-ме, түгел).*

Җөмләнең төп коммуникатив төрләре: хикәя, сорау җөмләләр. Татар җөмләсендә сүз тәртибе үзенчәлекләре. Җөмлә калыплары.

**Лексик минимум**

*Исәнме, мәктәп!*

Исәнмесез, исәнме, сәлам, дәфтәр, китап, бу, кем, нәрсә, әйе, юк, түгел, мин, син, ул, рәхмәт, сау бул, сау булыгыз, утыр, утырыгыз

*Гаилә*

Гаилә, кеше, әти, әни, абый, апа, эне, сеңел, бала, әби, бабай, малай, кыз, нинди, сан, ничә, укучы, укытучы, тату, яшь, кеше, гафу итегез

*Сәламәт бул!*

Баш, колак, чәч, авыз, борын, күз, тел, теш, кул, бармак, сул, уң, аяк, сәламәт булырга, төс, кызыл, сары, яшел, зәңгәр, ак, кара, соры, коңгырт, алма, зур, кечкенә, кирәргә, чыгарга, ярый

*Шәһәрдә*

Шәһәр, урам, йорт, кибет, мәйдан, кунакханә, киң, тар, озын, кыска, биек, тәбәнәк, матур

*Уенчыклар кибетендә*

Уенчык, йомшак, күп, бик, курчак, туп, шакмак, аю, төлке, куян, сатучы, алырга, карарга, сөйләргә, уйнарга, укырга

*Киемнәр кибетендә*

Кием, күлмәк, чалбар, итәк, тун, бүрек, күн итек, бияләй, шәл, алырга, сатарга, базар, без, сез, алар, барырга, кирәк (түгел), рәхим итегез

*Ашамлыклар кибетендә*

Икмәк, күмәч, сөт, чәй, конфет, май, шикәр, туңдырма, ашарга, эчәргә

*Ел фасыллары*

Ел фасылы, кыш, яз, җәй, көз, җылы, салкын, аяз, кар ява, болытлы, кояш, җил исә, яңгыр ява, яратырга, яхшы, әйбәт, бик яхшы, шәп, хәерле иртә (көн, кич)

*Яңа ел бәйрәме*

Бәйрәм, күңелле, Яңа ел, бүләк, бирергә, котларга, Кыш бабай, Кар кызы, чыршы, теләргә, бәхет, шатлык, бизәргә, белән, кайтырга

*Без кунакка барабыз*

Кунак, чынаяк, пычак, кашык, балкалак, чәнечке, тәлинкә, бал, чәкчәк, гөбәдия, өчпочмак, кыстыбый, пәрәмәч, коймак, тәмле

*Без уйныйбыз, җырлыйбыз*

Уйнарга, җырларга, җыр, җырчы, биергә, бию, биюче, шигырь, гармун, курай, ничәнче, бүген, иртәгә, кичә, иртән, кичен, көндез, турында

*Йорт хайваннары һәм кошлары*

Хайван, сыер, бозау, ат, колын, сарык, кәҗә, эт, песи, кош, әтәч, тавык, каз, үрдәк, күркә, чеби, кычкырырга, мияуларга, өрергә

*Кыргый хайваннар һәм кошлар*

Урман, кыргый, бүре, куян, керпе, тиен, фил, арыслан, усал, куркак, хәйләкәр, чыпчык, күгәрчен, карга, тукран, очарга. кызыксынырга

*Әниләр бәйрәме*

Булышырга, савыт-саба, үтүкләргә, юарга, сөртергә, идән, тузан, пешерергә, чәчәк

*Бакчада*

Бакча, кыяр, кишер, суган, бәрәңге, кәбестә, яшелчә, җиләк, җимеш, агач, үсәргә, җыярга, чүп утарга, җир казырга, утыртырга, су сибәргә, чүп үләне, эшләргә, ял итәргә

*Без спорт яратабыз*

Чана, чаңгы, җиңүче, җиңәргә, сикерергә, йөгерергә, катнашырга, шуарга, кышкы, җәйге, көрәш, көчле

*Җәйге ял*
Су коенырга, кызынырга, балык тотарга, күл, елга, рәхәт, саф һава, йөрергә, җәяү, табигать, диңгез

## 2 нче сыйныф

**Сөйләм эшчәнлегенең төрләре буенча күнекмәләр**

***Сөйләү***

– сөйләм этикеты үрнәкләрен кулланып, үрнәк буенча диалоглар төзү;
– предметны, персонажны яки рәсемне тасвирлау;
– йорт (фатир), көндәлек режим, кунакка бару, туган ягыбыз - Татарстан, аның башкаласы, ял итү турында сөйләү;
– укылган (тыңланган) текстның эчтәлеген кыскача сөйләү;
- лексик тема буенча сөйләшү үткәрү (һәр укучының репликалар саны 4 тән ким булмаска тиеш);
- лексик тема яки сюжетлы рәсемнәр буенча хикәя төзеп сөйләү (җөмләләр саны 5 тән ким булмаска тиеш);

***Тыңлап аңлау***

– 0,5 минутлык текстны тыңлап аңлау һәм, төп эчтәлегенә төшенеп, укытучының сорауларына җавап бирү;
- диалогны тыңлау, анда сүз нәрсә турында баруын әйтү;
- текстны тыңлау һәм бирелгән җөмләләр арасында эчтәлегенә туры килгәннәрен билгеләү.

***Уку***

– текстларны сәнгатьле итеп уку һәм укыганның эчтәлегенә тулысынча төшенү;
- тексттагы яңа сүзләрнең мәгънәләрен контексттан чыгып аңлау яки сүзлектән табу;
-текстны эчтән укып, кирәкле мәгълүматны табу һәм аңа бәйле гади нәтиҗәләр ясау;
- шигырьләрне яттан сөйләү.

***Язу***

- хәрефләрне һәм сүзләрне дөрес язу;
- аерым җөмләләрне, кечкенә текстларны үзгәрешсез күчереп язу;
- әйтелеше белән язылышы арасында аерма булмаган сүзләрне дөрес язу;
- бирелгән үрнәк буенча котлау язу;
– өйрәнелгән тема буенча сорауларга язмача җавап бирү;
– сөйләм бурычын аңлап, үз фикереңне кыскача язмача белдерү.

**Тел чаралары һәм аларны куллану күнекмәләре**

***Сөйләмнең фонетик ягы***

– үзенчәлекле авазларны ишетеп аера һәм дөрес әйтә белү;
– калын һәм нечкә әйтелешле сүзләрне аера белү;
– сүзләрдә басымны дөрес кую;
– әйтү максаты ягыннан җөмлә төрләрен аеру;
– ритм һәм интонация үзенчәлекләрен исәпкә алып, җөмләләрне дөрес әйтү;
– текстны үзгәртмичә күчереп язу;
– актив үзләштерелгән сүзләрне дөрес әйтү һәм язу;
– татар теленең үзенчәлекле авазларын транскрипция билгеләре белән күрсәтү.

***Сөйләмнең лексик ягы***

– аралашу барышында, коммуникатив максаттан чыгып, актив лексикадан файдалану;
– аралашу темаларына караган лексик берәмлекләрне һәм сөйләм гыйбарәләрен куллана белү.

***Сөйләмнең грамматик ягы***

– өйрәнелгән грамматик формаларны сөйләмдә дөрес куллану һәм тексттан табып әйтү;

– җөмләнең төп коммуникатив төрләрен  сөйләмдә куллану.

**Социаль-мәдәни күнекмәләр**

Татарстан Республикасының шәһәрләре һәм елгалары, башкаласының истәлекле урыннары, татар халкының күренекле шәхесләре, татар халкының милли бәйрәмнәре һәм гореф-гадәтләре турында мәгълүматлы булу.

**Махсус күнекмәләр**

Ике телле сүзлекләрдән, таблицалардагы белешмә материалдан, мультимедиа әсбапларыннан файдалану; сүзлекчә (сүзлек дәфтәре) алып бару.

**Сөйләмнең предмет эчтәлеге**

Телдән һәм язма сөйләмнең эчтәлеге белем һәм тәрбия бирү максатларыннан, шулай ук укучыларының яшь үзенчәлекләре һәм мәнфәгатьләреннән чыгып билгеләнә.

*Яңа уку елы белән!*
*Йортыбыз. Фатирыбыз*
*Көндәлек режим .*
*Ашамлыклар кибетендә*
*Әбиләрдә кунакта*
*Табигатьтәге үзгәрешләр*
*Татарстан - туган ягым*
*Казан – Татарстанның башкаласы*
*Сәламәтлек – иң зур байлык*
*Без хезмәт яратабыз*
*Үсемлекләр белән танышабыз*
*Хайваннарга һәм кошларга булышабыз*
*Без  бәйрәмгә барабыз*
*Күңелле ял итәбез*

**Тел материалы**

*Фонетика.*  Аваз-хәреф мөнәсәбәтләре. Транскрипция билгеләре. Татар телендәге барлык авазларны ишетеп тану. Калын һәм нечкә әйтелешле сүзләр. Сингармонизм законы. Сингармонизм законына буйсынмаган сүзләр (*пенал, китап,  миңа, сиңа)*. Үзенчәлекле тартык авазлы ([къ], [гъ], [w], [ж], [ң], [һ], [ч]) сүзләр. Ике тартык янәшә килгән сүзләр (*кайтты, китте). Я, ю, е* хәрефләре булган сүзләр**:** *ярата* [йарата], *яши* [йәши], *юл* [йул], *ел* [йыл]. Кыска һәм озын сузыклар.  Яңгырау тартыкларның иҗек яки сүз ахырында саңгыраулашуы. Нечкәлек яки калынлык билгесе булган гади сүзләрнең
*(сәгать, шигырь),* кушма сүзләрнең *(көньяк, кулъяулык)*
әйтелеше. Басым соңгы иҗеккә төшмәгән сүзләр (*сорау алмашлыклары, -мы/-ме кисәкчәле сүзләр, алынма сүзләр).* Хикәя, боеру, тойгылы җөмләләрнең ритмик-интонацион үзенчәлекләре. Санау интонациясе. Сөйләм әдәбе үрнәкләрендә интонация.

Уку һәм язу кагыйдәләре. Сүзне юлдан-юлга күчерү. Җөмләне баш хәрефтән яза башлау. Ялгызлык исемнәрне баш хәрефтән язу. Җөмлә ахырында тыныш билгеләре (нокта, сорау һәм өндәү билгеләре).

*Лексика.* Аралашу темаларына караган лексик берәмлекләрне рецептив һәм продуктив рәвештә үзләштерү. Гади тотрыклы гыйбарәләр; сөйләм әдәбе берәмлекләре.  Алынма сүзләр (мәсәлән, *компьютер, фильм*). Сүз ясалышы турында беренчел мәгълүмат бирү: парлы (*савыт-саба*), кушма (*ташбака*) һәм тезмә (*салават күпере*) сүзләр. Сүз ясагыч кушымчалар *–лы/-ле (бәхет – бәхетле).*

*Грамматика.*  Исемнәрнең сан һәм килеш белән төрләнеше. Исемнәрнең тартым белән төрләнеше. *Иялек килешендәге исем + тартымлы исем (укучының дәфтәре)* төзелмәсе. Ялгызлык исемнәр.  Лексик темаларга караган сыйфатлар. Зат, сорау, күрсәтү (*бу,  менә*) алмашлыклары. Зат алмашлыкларының килеш белән төрләнеше. Микъдар саннары (100 гә кадәр), тәртип саннары (100 гә кадәр). Хәзерге заман, билгеле үткән заман хикәя фигыльләрнең барлыкта һәм юклыкта зат-сан белән төрләнеше. *Кирәк (түгел), мөмкин (түгел), ярый, ярамый*

сүзләрен фигыльнең инфинитив формасы белән кулланылышы. Урын рәвешләре (*анда, монда).* Бәйлекләрнең исемнәр һәм алмашлыклар белән кулланылышы (*белән, турында, өчен, саен, кебек, кадәр, соң).* Кисәкчәләр (*әле, бик). Һәм, ә* теркәгечләре.

Җөмләнең төп коммуникатив төрләре: хикәя, сорау, боеру җөмләләр. Раслау һәм инкарь җөмләләр. Татар җөмләсендә сүз тәртибе. Җөмлә калыплары.

**Лексик минимум**

*Яңа уку елы белән!*

Белем, белергә, өйрәнергә, тыңларга, аңларга, кабатларга, сорау, сорау бирергә, җавап, җавап бирергә, тәрҗемә итәргә, мисал, күнегү, билге алырга, бишле, дүртле, өчле, икеле, аваз, хәреф, сүз, җөмлә, өтер, нокта, тәнәфес, ярый (ярамый)

*Йортыбыз, фатирыбыз*

Бүлмә, алгы бүлмә, аш бүлмәсе, кунак бүлмәсе, аш бүлмәсе, йокы бүлмәсе, юыну бүлмәсе, ишек, ачкыч, тәрәзә, тәрәзә төбе, гөл, сәгать, идән, түшәм, җиһаз, өстәл, журнал өстәле, язу өстәле, урындык, кәнәфи, элгеч, карават, киштә, суыткыч, кием шкафы, савыт-саба шкафы, келәм, якты, чиста

*Көндәлек режим*

Дүшәмбе, сишәмбе, чәршәмбе, пәнҗешәмбе, җомга, шимбә, якшәмбе, башта, аннары, тагын, торырга, йокларга ятарга, юынырга, сөртенергә, киенергә, дәрес әзерләргә, сөлге

*Ашамлыклар кибетендә*

Ашамлык, балык, каймак, эремчек, он, ит, тоз, шикәр комы, прәннек, тартма, акча, сум, тиен (копейка), сайларга, түләргә, үлчәргә

*Әбиләрдә кунакта*

Кунак, чакырырга, күчтәнәч, табын, ашъяулык, кулъялык, токмачлы аш, шулпа, ботка, сыйларга, салырга, бәхетле, шатлыклы, тәрбияле, рәхмәт әйтергә, әле, бик

*Табигать*

Табигать, кышын, язын, көзен, җәен, боз каплый, тамчы тама, кар эри, гөрләвек ага, яшен яшьни, күк күкри, салават күпере чыга, көн кыскара, төн озыная, соң (после), пычрак, бераз

*Татарстан — туган җирем*

Җир, туган, халык, Алабуга, Чистай, Яр Чаллы, Түбән Кама, Әлмәт, Бөгелмә, Нократ, Идел, Казансу, Агыйдел, урнашкан, елга ага, аша (аркылы), өчен, кадәр, буенда, чишмә, дала, төзергә, төзелеш, мәчет, чиркәү, тимер юл, бай

*Казан — Татарстанның башкаласы*

Башкала, бина, манара, үзәк, ашханә, даруханә, истәлекле урын, сарай (дворец), тукталыш, иске, яңа, ерак, якын, туктарга, анда, монда, таныш, тапкыр (раз), алда, артта

*Сәламәтлек — зур байлык*

Сәламәт, сәламәтлек, авырый, авырта, йөткерә, йөрәк, эч, табиб(ә), хастаханә, дәваларга, ятарга, шөгыльләнергә, ишетергә, күрергә, сирәк, еш, ярый, ярамый

*Без хезмәт яратабыз*

Тырыш, ялкау, ярдәмчел, хезмәт, ташырга, ташларга, чүп, чиләк, чүпрәк, ябарга, ачарга, чыгарга, керергә, яме, һәрвакыт, кайвакыт, үзе

*Үсемлекләр белән танышабыз*

Үсемлек, үлән, ботак, яфрак, имән, каен, нарат, алмагач, шомырт, миләш, балан, карлыган, кура җиләге, җир җиләге, чия

*Хайваннарга һәм кошларга булышабыз*

Җим, җимлек, ясарга, файда китерә, зыян китерә, өн, оя, күсе, тычкан, көньяк, төньяк, кышларга, тышта, ашатырга

*Без бәйрәмгә барабыз*

Тамаша, тамашачы, сәхнә, чыгыш, баянчы, кул чабарга, яраткан, Җиңү бәйрәме, Яз һәм Хезмәт бәйрәме, Сабантуй, көрәш, ат чабышы, аркан тартышу, шома баганага менү, чүлмәк вату, капчык белән сугышу

*Күңелле ял итәбез*

Ял итәргә, ямьле, күтәргә, каршыларга, сагынырга, озатырга, үткәрергә, йөзәргә, әбәкле уйнарга, качышлы уйнарга, таган атынырга, ком, кәрзин, тулы, буш, күбәләк оча, кошлар сайрый

**3 нче сыйныф**

**Сөйләм эшчәнлегенең төрләре буенча күнекмәләр**

***Сөйләү***

– сорау яки җавап репликаларын өстәп, диалог төзү;
- укылган яки тыңланган текстның төп эчтәлеге буенча сораулар кую һәм җавап бирү;
- лексик тема буенча сөйләшү үткәрү (һәр укучының репликалар саны 5 тән ким булмаска тиеш);
- сөйләм ситуациясе яки рәсем буенча хикәя төзеп сөйләү (җөмләләр саны 6 дан ким булмаска тиеш);
- хикәянең ахырын уйлап бетерү һәм сөйләү;
- укылган яки тыңланган текстның төп эчтәлеген сөйләп бирү.

***Тыңлап аңлау***

– аралашу барышында сыйныфташларның сөйләмен ишетеп аңлау һәм җавап кайтару;
– укытучының күрсәтмәләрен бер әйтүдән тулысынча аңлап бару;
- 0,5 минутлык текстны тыңлап, аның төп эчтәлеген сөйләп бирү.

***Уку***

– төрле жанрлардагы текстларны эчтән яки кычкырып уку һәм төп эчтәлегенә төшенү;
- укылган тексттагы таныш булмаган сүзләрнең мәгънәләрен аңлау;
- татар халык авыз иҗаты үрнәкләрен (мәкальләр, санамышлар, тизәйткечләр, табышмаклар) яттан әйтү;
- шигырьләрне яттан сөйләү.

***Язу***

– актив үзләштерелгән сүзләрне яттан язу;
- лексик тема яки сюжетлы рәсемнәр буенча хикәя язу;
- укылган яки тыңланган текстның эчтәлеге буенча сорауларга язмача җавап бирү;
- бәйрәм белән котлау язу.

**Тел чаралары һәм аларны куллану күнекмәләре**

***Сөйләмнең фонетик ягы***

– лексик темаларга караган үзенчәлекле авазлы сүзләрне дөрес әйтә белү;
– аерым сүзләрдә, фразада басымны дөрес кую;
– әйтү максаты ягыннан җөмлә төрләрен аеру;
– ритм һәм интонация үзенчәлекләрен исәпкә алып, җөмләләрне дөрес әйтү.
– актив үзләштерелгән сүзләрне дөрес уку һәм язу;
– текстны үзгәртмичә күчереп язу;
– татар теленең үзенчәлекле авазларын транскрипция билгеләре белән күрсәтү.

***Сөйләмнең лексик ягы***

– аралашу барышында, коммуникатив максаттан чыгып, актив лексикадан файдалану;
– өйрәнелгән аралашу темаларына караган лексик берәмлекләрне һәм сүтезмәләрне тану.

***Сөйләмнең грамматик ягы***

– өйрәнелгән грамматик формаларны сөйләмдә дөрес куллану һәм тексттан табып әйтү;
– җөмләнең төп коммуникатив төрләрен сөйләмдә куллану.

**Социаль-мәдәни күнекмәләр**

Татарстанның һәм Казанның тарихы, истәлекле урыннары, театрлары, татар халкының күренекле шәхесләре, бәйрәмнәр, милли ашлар турында мәгълүматлы булу.

**Махсус күнекмәләр**

Ике телле сүзлекләрдән файдалану; таблицаада бирелгән белешмә материалдан файдалану; мультимедиа әсбапларыннан файдалану; сүзлекчә (сүзлек дәфтәре) алып бару.

**Сөйләмнең предмет эчтәлеге**

Телдән һәм язма сөйләмнең эчтәлеге белем һәм тәрбия бирү максатларыннан, шулай ук укучыларының яшь үзенчәлекләре һәм мәнфәгатьләреннән чыгып билгеләнә.

*Белем бәйрәме*
*Сәламәт булыгыз!*
*Спорт уеннары*
*Ашханәдә*
*Базарда*
*Без театрга барабыз*
*Бәйрәмнәр*
*Һөнәрләр*
*Татарстан – безнең Ватаныбыз*
*Әти-әниләргә булышабыз*
*Без сәяхәткә чыгабыз*

**Тел материалы**

*Фонетика*. Лексик темаларга караган калын һәм нечкә әйтелешле сүзләр. Басым беренче иҗеккә төшкән сүзләр. Алынма сүзләрнең әйтелеше. Янәшә килгән ике тартык булган сүзләрнең әйтелеше һәм аваз үзгәрешләре *(исә**нм**есез, у**нб**ер, боры**нг**ы*). Янәшә килгән ике бертөрле тартык булган сүзләрнең әйтелеше *(а**кк**ош, э**сс**е*). [р] авазына башланган сүзләрнең әйтелеше ['рәсем], [ырам]. *Я, ю, е* хәрефләре белдергән авазлар: *яшел* [йәшел]; *яңа* [йа°ңа], *юл* [йул]; *егет* [йэгэт]; *ел* [йыл].

*Лексика.* Аралашу темаларына караган лексик берәмлекләрне рецептив һәм продуктив рәвештә үзләштерү. Гади тотрыклы гыйбарәләр; сөйләм әдәбе берәмлекләре. Татар һәм рус телләре өчен уртак сүзләр. Алынма сүзләр (мәсәлән, *театр, спектакль*). Сүз ясалышы турында мәгълүмат бирү: парлы (*көн-төн*), кушма (*көнчыгыш*) һәм тезмә (*энҗе чәчәк*) сүзләр. Сүз ясагыч кушымчалар: *-лык/-лек (дәреслек, шатлык).*

*Грамматика.* Сан, тартым, килеш белән төрләнгән исемнәр. Килеш белән төрләнгән зат алмашлыклары, күрсәтү, сорау алмашлыклары. Лексик темаларга караган сыйфатларның чагыштыру дәрәҗәсе. Билгесез үткән заман хикәя фигыльләрнең барлыкта һәм юклыкта зат-сан белән төрләнеше. *Алдында, артында, өстендә, астында, янында* бәйлек сүзләре. *Ләкин, чөнки* теркәгечләре. *Әле, инде* кисәкчәләре. *Кебек (шикелле), аркылы, саен, бирле* бәйлекләре.

Җөмләнең төп коммуникатив төрләре: хикәя, сорау, тойгылы, боеру җөмләләр. Татар җөмләсендә сүзләрнең урнашу тәртибе һәм үзара бәйләнеш үзенчәлекләре. Раслау һәм инкарь җөмләләр. Җөмлә калыплары.

**Лексик минимум**

*Белем бәйрәме*

Дәрес, дәреслек, сүзлек, көндәлек, бетергеч, сызгыч, уку, язу, хата, дөрес, рәсем, рәсем ясарга, буяу, җилем (клей), өй эше, бирем, эш дәфтәре, кайчы, кәгазь, төсле кәгазь, карандаш очлагыч

*Сәламәт булыгыз!*

Сәламәт, дару, даруханә, дәваланырга, терелергә, сызларга, тамак, салкын тияргә, чыныгырга, онытырга, таза, ябык, симез, файдалы, дару үләннәре, мәтрүшкә, гөлҗимеш, кычыткан

*Спорт уеннары*

Кышын, җәен, уен, кызыклы, кәшәкә, тимераяк, шугалак, тау, шаярырга, шаян, рәхәт, дуслык, оста, шахматчы, буенча, беренчелек

*Ашханәдә*

Аш, ашханә, иртәнге аш, көндезге аш, кичке аш, кәбестә ашы, токмач ашы, пылау, пилмән, ботка, дөге, солы, карабодай, тавык ите, алма пирогы, йомырка, кесәл, ач, тук, әдәпле

*Базарда*

Җиләк-җимеш, кавын, карбыз, әфлисун, чикләвек, өрек, йөзем, борыч, сарымсак, чөгендер, шалкан, кабак, чәчәк бәйләме, роза чәчәге, лалә, энҗе чәчәк, ак чәчәк

*Без театрга барабыз*

Тамаша, тамаша залы, тамашачы, көй, башкаручы, башкарырга, ошарга, оста, осталык, сәхнә, пәрдә ачыла, ябыла, рәхмәтле булырга

*Бәйрәмнәр*

Тантана, кичә (вечер), халыкара, милли, дини, Нәүрүз бәйрәме, карга боткасы, бәйрәм итәргә, табышмак, башваткыч, тизәйткеч, берничә, үткәрергә

*Һөнәрләр белән танышабыз*

Һөнәр, танышырга, төзүче, тегүче, балыкчы, рәссам, язучы, шагыйрь, шигырь, тәрбияче, китапханәче, пешекче, нефтьче, машина йөртүче, хат ташучы, урманчы, эшләргә, булып

*Татарстан — безнең Ватаныбыз*

Ватан, тарих, дәүләт, ил башлыгы, көнчыгыш, көнбатыш, көньяк, төньяк, күрше, халык, күпчелек, авыл хуҗалыгы, чикләшергә, бәйләнеш, тыгыз, чит, җитештерергә, кара алтын, горурланырга

*Әти-әниләргә булышабыз*

Хуҗа, хуҗабикә, хуҗалык, булышырга, кер юу машинасы, тегү машинасы, тегәргә, бәйләргә, чигәргә, пычак, чүкеч, кисәргә, кадак кагарга, такта, пычкы, балта, утын ярырга

*Без сәяхәткә чыгабыз*

Сәяхәт, сәяхәт итәргә, сәяхәтче, юлдаш, башка (другой), чит ил, җыенырга, саен, һәр, диңгез, тау башында, күл буенда, күл төбендә, урман буйлап, чишмә, җәяү, учак ягарга, иң, теге

## 4 нче сыйныф

**Сөйләм эшчәнлегенең төрләре буенча күнекмәләр**

***Сөйләү***

- сөйләм әдәбе үрнәкләрен урынлы кулланып, сөйләшү үткәрү;
- укылган яки тыңланган текстның эчтәлеге буенча әңгәмә кору;
– аралашу ситуацияләренә бәйле диалог төзеп сөйләү (һәр укучының репликалар саны 6 дан ким булмаска тиеш);
- тасвирлау һәм хикәяләү элементларын кертеп, лексик тема буенча эзлекле сөйләм оештыру (җөмләләр саны 7 дән ким булмаска тиеш);
- укылган яки тыңланган текстның эчтәлеген сөйләгәндә, төрле җөмлә калыпларын куллану һәм фикерне эзлекле белдерү.

***Тыңлап аңлау***

– укытучы әйткәнне тыңлап аңлау;
- 0,5 минутлык текстны тыңлап, эчтәлеге буенча сөйләшүдә катнашу;
- дәрестә катнашучыларның җанлы сөйләмен тыңлап, эчтәлегенә төшенү.

***Уку***

– төрле жанрлардагы текстларны сәнгатьле итеп һәм аңлап уку;
- тексттагы яңа сүзләрнең мәгънәләрен контексттан чыгып аңлату;
- татар балалар язучылары әсәрләреннән алынган өзекләрне укып, эчтәлеген сөйләү;
- шигырьләрне яттан сөйләү.

**Язу**

- гаилә-көнкүреш һәм уку хезмәтенә бәйле темаларга яки сюжетлы рәсемнәр буенча кечкенә сочинение язу;

- тыңланган яки укылган текстның эчтәлеге буенча сорауларга язмача җавап бирү;
- аерым сүзләрне, җөмләләрне, бәйләнешле текстны үзгәрешләр кертеп язу.

**Тел чаралары һәм аларны куллану күнекмәләре**

***Сөйләмнең фонетик ягы***

– үзенчәлекле авазлы сүзләрне дөрес әйтә белү;
– аерым сүзләрдә, фразада басымны дөрес кую;
– әйтү максаты ягыннан җөмлә төрләрен аеру;
– ритм һәм интонация үзенчәлекләрен исәпкә алып, җөмләләрне дөрес әйтү.
– җөмләләрне, текстларны үзгәрешләр кертеп язу;
– актив үзләштерелгән сүзләрне дөрес уку һәм язу;
– татар теленең үзенчәлекле авазларын транскрипция билгеләре белән күрсәтү.

***Сөйләмнең лексик ягы***

– аралашу барышында, коммуникатив максаттан чыгып, актив лексикадан файдалану;
– өйрәнелгән аралашу темаларына караган лексик берәмлекләрне һәм сүзтезмәләрне тану.

***Сөйләмнең грамматик ягы***

– өйрәнелгән грамматик формаларны сөйләмдә дөрес куллану һәм тексттан табып әйтү;
– җөмләнең төп коммуникатив төрләрен сөйләмдә куллану.

**Социаль-мәдәни күнекмәләр**

Татарстан Республикасының дәүләт символлары, тарихи урыннары, музейлары, табигый байлыклары, татар халкының күренекле шәхесләре турында мәгълүматлы булу.

**Махсус күнекмәләр**

Ике телле сүзлекләрдән файдалану; таблица, схема рәвешендә бирелгән белешмә материалдан файдалану; аудио- һәм видеоәсбаплардан файдалану; сүзлекчә (сүзлек дәфтәре) алып бару.

**Сөйләмнең предмет эчтәлеге**

Телдән һәм язма сөйләмнең эчтәлеге белем һәм тәрбия бирү максатларыннан, шулай ук укучыларының яшь үзенчәлекләре һәм мәнфәгатьләреннән чыгып билгеләнә.

*Мәктәптә (12 сәгать).*
*Татарстан Республикасының дәүләт символлары*
*Татарстанның тарихы белән танышабыз*
*Табигатьне саклыйбыз*
*Музейларга барабыз*
*Универмагта*
*Һөнәрләр*
*Зоопаркта*
*Исәнме, җәй!*

**Тел материалы**

*Фонетика.* Лексик темаларга караган сүзләрнең әйтелеше. Әйтелеше белән язылышы арасында аерма булган сүзләр. Сүзләрне, аерым җөмләләрне үзгәрешләр кертеп язу. Кеше исемнәрен һәм фамилияләрен, шәһәр, авыл һәм елга исемнәрен, хайван кушаматларын баш хәрефтән язу.

*Лексика.* Аралашу темаларына караган лексик берәмлекләрне рецептив һәм продуктив рәвештә үзләштерү. Гади тотрыклы гыйбарәләр; сөйләм әдәбе берәмлекләре. Алынма сүзләр (мәсәлән, *гимн, герб, флаг*). Сүз ясалышы: кушма (*урынбасар*) һәм тезмә (*бака яфрагы*) сүзләр. Сүз ясагыч кушымчалар: *-чы/-че (тәрҗемәче, урманчы).*

*Грамматика.* Берлек һәм күплек сандагы уртаклык һәм ялгызлык исемнәр. Актив үзләштерелгән сыйфатларның төп, чагыштыру һәм артыклык дәрәҗәләре. Хикәя фигыльнең өйрәнелгән заман формалары. *Гына/генә, кына/кенә* кисәкчәләре. Күрсәтү

алмашлыклары *(бу, теге, әнә, менә). Таба, соң, кадәр* бәйлекләре. Билгеле киләчәк заман хикәя фигыльнең барлыкта һәм юклыкта зат-сан белән төрләнеше. Татар һәм рус җөмләләрендә сүз тәртибе үзенчәлекләре. Татар җөмләсендә сүзләрнең урнашу тәртибе һәм үзара бәйләнеш үзенчәлекләре.

Җөмләнең төп коммуникатив төрләре: хикәя, сорау, тойгылы, боеру җөмләләр. Раслау һәм инкарь җөмләләр. Җөмлә калыплары.

**Лексик минимум**

*Мәктәптә*

Акыллы, тапкыр, сәләтле, белемле, сабыр, уйларга, тикшерергә, санарга, кушарга, алырга (отнять), бүлергә, тапкырларга, чишәргә, мәсьәлә, чагыштырырга

*Татарстанның дәүләт символлары*

Дәүләт гербы, дәүләт флагы, дәүләт гимны, дәүләт теле, барлык (бөтен), тасма, намус, тынычлык, көч, халык, матурлык, канатлы, ак барс, боҗра, калкан, кашкарый, җилфердәргә, яңгырарга, хөрмәт итәргә

*Татарстанның тарихы белән танышабыз*

Болгар дәүләте, Казан ханлыгы, тарих, тарихи, хәтер, хәтерләргә, галим, ачыш, казаныш, үсеш алырга, Казан Кремле, Кол Шәриф мәчете, Благовещение соборы, Сөембикә манарасы, Спасс манарасы

*Табигатьне саклыйбыз*

Кызыл китап, сакларга, яхшыртырга, байлык, пычратырга, өзәргә, таптарга, агулы, зарарлы, саф һавалы, каршы, әллә, икән, йөрергә, шатланырга,

*Музейларга барабыз*

Күргәзмә, сынлы сәнгать, милли, саклanырга, корал, шәхси әйберләр, таш, мәрмәр, алтын, көмеш, сын, сынчы, гасыр, борынгы

*Универмагта*

Үзәк, бүлек, сатып алырга, сатарга, өй җиһазлары, бизәнү әйберләре, баш киемнәре, өс киемнәре, аяк киемнәре, алка, йөзек, муенса, беләзек, киеп карарга, килешергә (быть к лицу), игътибар, игътибарлы, ачык, ябык

*Һөнәрләр*

Оешма, җитәкче, эш, эшче, эшкуар, рәис, урынбасар, ярдәмче, тәрҗемәче, нефтьче, хисапчы, мактарга, ихтирам итәргә, тиеш

*Зоопаркта*

Дөя, фил, арыслан, юлбарыс, көнгерә, ишәк, бака, ташбака, маймыл, су үгезе, елан, ишәк, ләкләк, лачын, торна, бөркет, ябалак, тукран, аккош, акчарлак, шуышырга, читлек

*Исәнме, җәй!*

Озакламый, күптән (түгел), яңадан, әлбәттә, бигрәк тә, ашыгырга, күңел ачарга, аралашырга, кызыксынырга, мавыгырга, рәхәтләнеп, биредә (монда), тегендә (анда)